**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Об отмене ограничительных мероприятий (карантина), установленных на отдельных территориях Республики Татарстан в связи с их неблагополучием по заболеванию бешенством животных**

В связи с истечением 60 календарных дней после уничтожения последнего трупа больного восприимчивого животного и проведением противоэпизоотических и профилактических мероприятий, в соответствии со статьей $3^1$ Закона Российской Федерации от 14 мая 1993 года № 4979-I «О ветеринарии» **постановляю**:

1. Отменить ограничительные мероприятия (карантин), установленные в связи с неблагополучием по заболеванию бешенством животных на следующих отдельных территориях Республики Татарстан:

а) на территории личного подсобного хозяйства по улице Ямашева, дом 17, деревни Олуяз в Березкинском сельском поселении муниципального образования «Высокогорский муниципальный район Республики Татарстан» и территории радиусом 1 км от границ эпизоотического очага в Березкинском сельском поселении муниципального образования «Высокогорский муниципальный район Республики Татарстан»;

б) на территории личного подсобного хозяйства по улице Васильковой, дом 43, деревни Колосовка в Танайском сельском поселении муниципального образования «Елабужский муниципальный район Республики Татарстан» и территории радиусом 1 км от границ эпизоотического очага в Танайском сельском поселении муниципального образования «Елабужский муниципальный район Республики Татарстан».

2. Признать утратившим силу Указ Раиса Республики Татарстан от 14 мая 2025 года № 365 «Об установлении ограничительных мероприятий (карантина) на отдельных территориях Республики Татарстан в связи с их неблагополучием по заболеванию бешенством животных».

3. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Раис Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ

Казань, Кремль
19 июля 2025 года
№ 565

**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә хайваннар котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерү турында**

Котыру чиренә бирешүчән соңгы авыру хайванның үләксәсе юкка чыгарылган көннән 60 календарь көн узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә хайваннар котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерергә:

а) «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Каенлык авыл җирлеге Олыяз авылындагы Ямашев урамы 17 нче йортта урнашкан шәхси йорт хуҗалыгы территориясендә һәм «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Каенлык авыл җирлегендәге эпизоотия чыганагы чикләреннән 1 км радиустагы территориядә;

б) «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Танай авыл җирлеге Колосовка авылындагы Күкчәчәк урамы 43 нче йортта урнашкан шәхси йорт хуҗалыгы территориясендә һәм «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Танай авыл җирлегендәге эпизоотия чыганагы чикләреннән 1 км радиустагы территориядә.

2. Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә хайваннар котыру авырулы булганга, аларның имин булмавы сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында» 2025 елның 14 маендагы 365 номерлы Указы үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2025 ел, 19 июль
№ 565